**ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.06.2026 № 70

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында» Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 23 мартындагы 53 номерлы карарына нигезләнеп

КАРАР БИРӘМ:

1. 2039 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасы проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (2027 елга актуальләштерү).

2. Түбәндәгеләрне билгелик:

2.1. гавами тыңлауларны оештыручы-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты;

2.2. гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 25.06.2026 16 сәгать 00 минутта;

2.3. үткәрү урыны-Нурлат муниципаль районы, Нурлат шәһәре, Совет ур., 117 й., каб. № 12, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты конференц-залы;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар тапшырылырга мөмкин булган адрес: 423040, Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Совет ур., 117 й., каб. № 17, электрон адрес zhil.otdelnurlat@mail.ru, тел. (84345) 31919;

2.5. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр, искәрмәләр һәм заявкалар кабул итү вакыты-23.06.2026 елга кадәр (эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр).

3. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. К. Габдуллин;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А. Г. Морзаханов;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. И. Бәхтияров;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте һәм коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы Н.И. Долгова;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы Г. Ф. Вәлиәхмәтова

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына:

4.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проектында күрсәтелгән җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәре оешмаларына гавами тыңлаулар уздыру турында язма рәвештә хәбәр итүне тәэмин итәргә;

4.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проекты буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар оештырырга һәм уздырырга;

4.3. әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

4.4. гавами тыңлауларның йомгаклау документын Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә гавами тыңлаулар уздырылган көннән алып 3 эш көне эчендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Район башлыгы Д.А. Ишкинеев